**БЕЛДЕРҮ**

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктының 15 пунктчасы һәм 39.18 статьясы нигезендә, Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы түбәндәге характеристикалы җир кишәрлеген 20 елга арендага бирү турында хәбәр итә:

Кадастр номеры 16:23:140502:31, мәйданы 1001 кв.м, җир категориясе: «торак пунктлар җирләре», рөхсәт ителгән файдалану төре: « шәхси хуҗалык алып бару өчен » (Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматлар нигезендә), кишәрлекнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Янил авыл җирлеге, Вахит авылы, Урман урамы, 11 нче җир кишәрлеге.

Югарыда күрсәтелгән җир кишәрлеген арендага алырга кызыксынучы гражданнар аукционда катнашу нияте турында әлеге хәбәр басылып чыкканнан соң 30 көн эчендә язма рәвештә гариза (алга таба – гаризалар) бирергә хокуклы. Гаризаны гариза бирүче (ышанычлы зат) эш көннәрендә (дүшәмбе – җомга, эшләми торган бәйрәм көннәреннән, эшләми торган көннәр дип игълан ителгән көннәрдән, ял көннәре күчерелгән көннәрдән тыш) 8.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр (12.00 сәгатьтән сәгать 13.00 гә кадәр – төшке аш өчен тәнәфес белән) Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара шәһәре, Ленин ур., 15 нче йорт 101 кабинетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә тапшыра ала.

Гаризаларны кабул итү тәмамлану датасы – 2023 елның 23 ноябре, 15 сәгать 00 минут.